**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЛӘРКҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«13» август 2026 ел № 27

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Biләркүл авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы «Біләркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Біләркүл авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Біләркүл авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 30 номерлы карарына (2026 елның 12 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru/ һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Біләркүл авыл җирлеге
Советы рәисе В.С. Оренбургов